КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 ноябрь г.Казань № 1006

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2024 ел, 2 декабрь, 1088 нче карарына үгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2024 ел, 2 декабрь, 1088 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 30 декабрь, 1294 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып), 9 пунктның алтынчы абзацына «дару препаратлары (ашыгыч билгеләнештәге медикаментлардан башка), медицина әйберләре, дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итүгә шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин